**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

19.09.2016 № 928-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 20.04.2012 № 144-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының начар һава шартлары булган чорларда атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү чаралары планнарын килештерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм Табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 20.04.2012 № 144-п боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 07.05.2016 № 266-п, 24.09.2013 № 539-п боерыклары белән кертелгән үзгәрешләре нигезендә) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының начар һава шартлары булган чорларда атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү чаралары планнарын килештерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: Татарстан Республикасының атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташлаучы чыганаклары булган һәм «Атмосфера һавасын саклау турында"гы Федераль закон нигезендә начар һава шартлары килү турында фаразлар алганда атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү чараларын үткәрергә бурычлы булган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.05.2012 № 407 карары белән расланган Предприятиеләр һәм оешмалар исемлегенә кертелгән шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар. Мөрәҗәгать итүчеләр: дәүләт хезмәтен алучылар яисә аларның законда билгеләнгән тәртиптә тапшырылган ышанычнамә нигезендә гамәл кылучы вәкилләре (алга таба – Мөрәҗәгать итүче).»;

1.3 пунктында:

1.3.1 пунктын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

"1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Павлюхин ур., 75 й.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен Министрлыкның почта адресы: 420049, Татарстан Республикасы, Казан ш., Павлюхин ур., 75 й.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән алып 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән алып 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында килү:

«Павлюхин» тукталышына кадәр:

№ 2, 4, 5, 12, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77 автобуслар;

№ 6, 8, 12 троллейбуслар;

метро, «Сукно бистәсе» станциясенә кадәр.

Керү шәхесне таныклый торган документ буенча.»;

1.3.3 пунктчасын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

"1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге "Татарстан Республикасы рәсми порталы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайты адресы (алга таба, тиешенчә – Министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре): http://eco.tatarstan.ru, электрон почта адресы: eco@tatar.ru.»;

1.3.5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

"Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1, 1.3.1, 1.3.2, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.";

1.4 пунктын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

"1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

1999 елның 4 маендагы "Атмосфера һавасын саклау турында" № 96-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1999, № 18, 2222 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 10 гыйнварындагы "Әйләнә-тирәлекне саклау турында" № 7-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 7-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон), (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 16 маендагы "Дәүләт вазифаларын үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында" № 373 карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2011, № 22, 3169 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Экология кодексы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге "Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре" № 325 карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт

хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" № 880 карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Тәртип) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 22 маендагы "Татарстан Республикасында начар һава шартлары булган чорларда атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын җайга салу эшләрен оештыру турында" № 407 карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы" журналы, 2012, № 41, 1325 ст.) (алга таба – № 407 ТР МК карары;)

Госкомгидромет СССР тарафыннан 01.12.1986 расланган "Начар һава шартлары булган чорларда ташландыкларны җайга салу. РД 52.04.52-85" методик күрсәтмәләр (алга таба – Методик күрсәтмәләр);

РАО "ЕЭС России" тарафыннан 29.05.1998 расланган "Начар һава шартлары булган чорларда җылылык электр станцияләрендә һәм котельныйларда атмосфера һавасына ташландыкларны җайга салу турында нигезләмә. РД 153-34.0-02.314-98" (алга таба – РД 153-34.0-02.314-98).";

1.5 пунктында:

3 кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

"чик күләмдә рөхсәт ителгән ташландык – атмосфера һавасына карата зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыгы нормативы, ул химик матдә күләме яки массасы яисә химик матдәләрнең, микроорганизмнарның, башка төрле матдәләрнең кушылмасы буларак, стационар чыганаклардан һәм (яки) стационар чыганаклар җыелмасыннан атмосфера һавасына ташлау өчен мөмкин булган радиоактив матдәләрнең активлык күрсәткече буларак билгеләнә һәм аны үтәгәндә атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге таләпләрнең үтәлеше тәэмин ителә;";

түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелүче документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпвазифалы үзәкнең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм тапшыру, мөрәҗәгать итүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе (алга таба – КВҮ читтән торып эшләү урыны).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә аңлашыла. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаның тәкъдим ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 2 кушымтада китерелә.";

2 бүлектә:

2 бүлек аталышын түбәндәгечә бәян итәргә: «2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты";

"Стандарт таләбенең атылышы" графасының аталышын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы";

"Стандарт таләбенең эчтәлеге" графасының аталышын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге";

2.1 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

"№ 96-ФЗ Федераль законның 19 ст.; № 373 РФ ХӨкүмәте карары; № 407 ТР МК карарының 3 п.; Нигезләмәнең 3.3 пунктындагы 3.3.7 пунктчасы";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасындагы 2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле текстны өстәргә:

"№ 96-ФЗ Федераль законның 19 ст.; № 407 ТР МК карарының 3 п.; Нигезләмәнең 3.3 пунктының 3.3.7 пунктчасы";

2.4 пунктында:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы" графасында ", шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты" сүзләрен өстәргә;

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Чаралар планын килештерү гаризаны теркәгән вакыттан алып 7 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.";

2.5 пунктында:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы" графасында "мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле" сүзләреннән соң ", мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе" сүзләрен өстәргә;

"Стандартка карата таләпнең эчтәлеге" графасында түбәндәге эчтәлекле бишенче һәм алтынчы кызыл юлларны өстәргә:

"6. Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документлар күчермәләре.

7. Ышанычнамә (вәкил тарафыннан гаризага имза салынган очракта).

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);

кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп.

Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, шул исәптән "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасының эчтәлеген түбәндәгечә бәян итәргә: "Методик күрсәтмәләр";

2.6 пунктында:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы" графасында ", шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны шушы документлар белән эш итүче дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки оешмага тапшыру тәртибе" сүзләрен өстәргә;

"Стандартка карата таләпнең эчтәлеге" графасында түбәндәге эчтәлекле икенче һәм өченче кызыл юлларны өстәргә:

"Документларны алу ысуллары һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасын түбәндәгечә бәян итәргә:

"№ 210-ФЗ Федераль законның 7 ст. 1 өл. 2 п.";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасының 2.8 пунктын төшереп калдырырга;

2.9 пунктында:

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасында: икенче кызыл юлны төшереп калдырырга, түбәндәге эчтәлекле дүртенче кызыл юлны өстәргә:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасының эчтәлеген түбәндәгечә бәян итәргә: "Методик күрсәтмәләр";

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасындагы 2.11 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә: "Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр юк";

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасындагы 2.12 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Рөхсәт алу буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.

Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.";

2.13 пунктында:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы" графасында ", шул исәптән электрон рәвештә" сүзләрен өстәргә;

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Гариза кергән көнне";

2.14 пунктында:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы" графасын түбәндәгечә бәян итәргә:

"2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнар нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларын урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр";

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте һаваны кондиционерлау системасы, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.";

2.15 пунктында:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы" графасында ", шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазифаи затлар белән хезмәттәшлек итү саны һәм аларның озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникатив технологияләрдән файдаланып" сүзләрен өстәргә;

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;

дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, "Интернет" челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтүнең нәтиҗәләрен гариза белән документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырганда мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында алу мөмкинлеге (гариза белән документларны электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеген тормышка ашыргач);

хезмәт күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:

документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

шушы Регламентны дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан бозуларга карата прецендентлар (нигезле шикаятьләр) булу (прецендентларның, шикаятьләрнең Министрлыкның һәм Министрлыктагы территориаль идарәләрнең дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазифаи затларының гомуми санына карата мөнәсәбәте);

мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша җибәргәндә:

1. әгәр дә гариза белән документларның күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә – турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми;

2. әгәр дә гариза белән документларның күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә – бер мәртәбәдән артык түгел.

Мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://http://eco.tatarstan.ru/ сайтыннан, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, күпвазифалы үзәк аша, күпвазифалы үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша күрсәтелми";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт" графасын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Тәртипнең 2.4 пунктының "п" пунктчасы";

"Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге" графасындагы 2.16 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза белән сканер аша чыгарылган документларны электрон рәвештә, алга таба рөхсәт алганда документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшыру мөмкинлеге бар";

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәгечә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпвазифалы үзәге, күпвазифалы үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре";

3.1 пунктында:

3.1.1 пунктын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

"3.1.1. Стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларына рөхсәт бирү буенча административ процедура түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

гариза белән документларны кабул итү һәм теркәү;

ведомствоара гарызнамәләрне ясау һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның тупланышын тикшерү, мөрәҗәгать итүченең материалларын карау, рөхсәтне (рөхсәт бирүдән баш тартуны) әзерләү һәм раслау,

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

техник хатаны төзәтү.";

3.2 пунктын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

"3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче Министрлыкның әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән, почта аша, телефоннан, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефоннан, электрон почта һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның рәвеше буенча һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләрдә консультацияләү, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.";

3.3 пунктында:

3.3.1 пунктчасында:

беренче кызыл юлда "эш башкару бүлеге" сүзләрен "документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге" сүзләренә алмаштырырга;

өченче кызыл юлны төшереп калдырырга;

3.3.2 пунктчасындагы беренче кызыл юлда "эш башкару бүлеге" сүзләрен "документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге" сүзләренә алмаштырырга;

3.3.3. пунктчасында:

икенче кызыл юлдагы "бер көн эчендә" сүзләрен "бер эш көне эчендә" сүзләренә алмаштырырга;

3.3.4 пунктчасында:

бишенче кызыл юлдагы "өч көн эчендә" сүзләрен "өч эш көне дәвамында" сүзләренә алмаштырырга;

3.3.7 пунктчасында:

беренче кызыл юлда "эш башкару бүлеге" сүзләрен "документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге" сүзләренә алмаштырырга;

икенче кызыл юлдагы "өч көн" сүзләрен "өч эш көне" сүзләренә алмаштырырга;

өченче кызыл юлда "эш башкару бүлеге" сүзләрен "документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге" сүзләренә алмаштырырга;

3.3.8 пунктчасында:

беренче кызыл юлда "эш башкару бүлеге" сүзләрен "документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге" сүзләренә алмаштырырга;

икенче кызыл юлдагы "бер көн" сүзләрен "бер эш көне" сүзләренә алмаштырырга;

3.3.9 пунктчасында:

алтынчы кызыл юлда "4 көн" сүзләрен "ике эш көне" сүзләренә алмаштырырга;

3.3.12 пунктчасында:

икенче кызыл юлдагы "бер көн" сүзләрен "бер эш көне" сүзләренә алмаштырырга;

3.3.13. пунктчасында:

өченче кызыл юлны түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә: "Шушы пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагысы тәмамланган көндә башкарыла.";

түбәндәге эчтәлекле 3.4 пунктын өстәргә:

"3.4. Дәүләт хезмәте күпвазифалы үзәктә, КВҮ читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.";

түбәндәге эчтәлекле 3.5 пунктын өстәргә:

"3.5. Техник хаталарны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү.

3.5.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза (4 кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хатасы) булган документ;

техник хатасы (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкиле)тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә), яисә Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә.

3.5.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша электрон рәвештә терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза.

3.5.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хатасы (язу, хәреф

хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның чын нөсхәсен алып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша Министрлыкка техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның чын нөсхәсен тапшырган очракта документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу, хәреф хата, грамматик яки арифметик хата) ачыкланганнан соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.";

4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.6 пунктын өстәргә:

"4.6. 4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.";

5 бүлекне түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

"5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлыкның, шулай ук анындәүләт хезмәтен күрсәтүче вазифаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлыкның вазифаи затының яисә Министрлыктагы дәүләт гражданлык хезмәткәренең гамәлләрен (гамәл кылмавын) Министрлыкка шикаять итәргә хокуклы. Дәүләт хезмәтен күрсәтү сәбәпле министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да шикаять белән шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, аның вазифаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта.

5.2. Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Интернет-кабул итү, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, күпвазифалы үзәк аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәтен алучыларның шикаятендә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазифаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, аның вазифаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче шуларга нигезләнеп, Министрлыкның, аның вазифаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмаган дәлилләр.

5.4. Министрлыкка килгән шикаять шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазифаи зат тарафыннан аны теркәгәннән соң 15 эш көне дәвамында, ә Министрлыкның, аның вазифаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында карап тикшерелергә тиеш.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаять мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яки аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда Министрлык җибәргән язу һәм хәреф хаталарын төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазифаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

2-5 кушымталардагы "М.У." сүзләрен "М.У. (булган очракта)" сүзләренә алмаштырырга;

3 кушымтада:

"эш башкару бүлеге" сүзләрен "документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге" сүзләренә алмаштырырга;

"1 көн" сүзләрен "1 эш көне" сүзләренә алмаштырырга;

"4 көн" сүзләрен "2 эш көне" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының начар һава шартлары булган чорларда атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү чаралары планнарын килештерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 4 кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министры

________________________________________

кемнән: ________________________________

(шәхси эшмәкәрләр өчен:
Ф.И.О.,адресы (почта һәм (яки) электрон)

________________________________________
Юридик затларга: оешма аталышы,
адресы (почта һәм (яки) электрон)

**Техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза**

______________________________________________________________
(дәүләт хезмәтенең аталышы)

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән техник хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) турында хәбәр итәм.

Язылган: __________________________________________________________

Дөрес белешмәләр: _______________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта түбәндәгечә хәбәр җиткерүне сорыйм:

- электрон документ рәвешендә, шушы E-mail адресына: ______;
- почта аша таныкланган күчермә рәвешендә кәгазьдә шушы адрес буенча: ____________________________________________________________.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә(яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, ябуга, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның ризалыгын раслыйм.

Хәзергесе белән шунысын раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкил булган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча түбәндәге телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _____________.

| | | |
|---|---|---|
| __________________ | _____________ | (_____________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.).”; |

түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының начар һава шартлары булган чорларда атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү чаралары планнарын килештерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына
5 кушымта

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының начар һава шартлары булган чорларда атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын киметү чаралары планнарын килештерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган вазифаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы**

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр – Габделганиев Фәрит Солтан улы | 267-68-01<br>267-68-02 | Farid.Abdulganiev@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары – Камалов Рөстәм Илдар улы | 267-68-19 | Rustem.Kamalov1@tatar.ru |
| Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу идарәсе башлыгы – Шәһидуллина Рәисә Габдулла кызы. | 267-68-90 | Raisa.Shagidullina@tatar.ru |
| Әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу бүлеге башлыгы – Богатырев Сергей Адольфович | 267-68-81<br>267-68-49<br>264-49-37 | Sergey.Bogatyrjov@tatar.ru |
| Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге | 267-68-04<br>267-68-05 | eco@tatar.ru. |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигый ресурслардан файдалану һәм әйләнә-тирәлекне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы – Фәсхетдинов Марат Гайса улы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru. |

2. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев